ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2019 с.Старое Дрожжаное № 484

2020 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына «2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге карарның 1 пункты нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма
комитет Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Расланган
Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы карары белән
«__» ____________ 2019 № ____

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап торуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Урнашкан территориясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, 1 елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы карамагындагы Интернат | авыл җирлеге | 92 342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 141 713 |

Башкарма комитетның
эшләр идарәсе җитәкчесе: Д.Р. Сабирзянова